ГЛАВА
МУНИЦИПАЛЬНОГО
ОБРАЗОВАНИЯ
«ТИМЯШЕВСКОЕ
СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ»
ЛЕНИНОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЛЕНИНОГОРСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
«ТИМӘШ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»
МУНИЦИПАЛЬ
БЕРӘМЛЕГЕ
БАШЛЫГЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2024 елның 11 ноябре № 10

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Тимәш авыл җирлегенең Тимәш торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары нигезендә, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы белән, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 22 ноябрендәге 909 номерлы карары белән расланган (29.11.2023 №1532 редакциясендә) Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына гражданнарның үзара салым акчаларын җәлеп итеп гамәлгә ашырыла торган җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибенең 2 пункты белән, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Тимәш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 24.1 маддәсе белән, Лениногорск муниципаль районы «Тимәш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгы КАРАР БИРДЕ:

1. Лениногорск муниципаль районы Тимәш авыл җирлегенең Тимәш торак пунктында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын 2024 елның 23 ноябрендә 11 сәгать 00 минутка билгеләргә.

2. Лениногорск муниципаль районы Тимәш авыл җирлегенең Тимәш торак пунктында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын 2024 елның 23 ноябрендә 13 сәгать 00 минутка билгеләргә.

3. Лениногорск муниципаль районы Тимәш авыл җирлегенең Тимәш торак пунктында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының өченче этабын 2024 елның 23 ноябрендә 15 сәгать 00 минутка билгеләргә.

4. Лениногорск муниципаль районы Тимәш авыл җирлегенең Тимәш торак пунктында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча

гражданнар җыенының дүртенче этабын 2024 елның 23 ноябрендә 17 сәгать 00 минутка билгеләргә.

5. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез Лениногорск муниципаль районы Тимәш авыл җирлегенең Тимәш торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1, 2 төркем инвалидлардан; хәрби хәрәкәтләрдә катнашучылардан; мобилизацияләнгән гражданнардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан; контракт хезмәте хәрби хезмәткәрләреннән һәм аларның гаилә әгъзаларыннан; көндезге бүлектә белем алучы студентлардан; ялгыз пенсионерлардан тыш, 2025 елда 300 (Өч йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән ризамы:

1) торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Тимәш торак пунктында Киров, Урман, Яшьләр, Нефтьүткәргечләр, Октябрь, Чишмә, Төньяк, Тукай, Мәктәп урамнары буйлап юлларны кардан чистарту; Тукай урамындагы юлның чокырларын асфальт түшәп ремонтлау);

2) торак пункт территориясен төзекләндерү (Тимәш торак пунктында җәйге вакытта кулдан үлән чабу (килешү буенча түләү)).

«РИЗА» «КАРШЫ».

3. Әлеге карарны түбәндәге адрес буенча урнашкан мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә: Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Тимәш авылы, Утыз Имәни урамы, 71А йорты, җирле үзидарә бинасы, Киров урамы, авыл мәдәният йортының 2-бинасы, Нефтепроводчиклар урамы, Ромашкино РНУ БПО утырышларының 20-залы, Киров ур., 1А-йорты «Ласточка» балалар бакчасы бинасы, Урман ур., 20, Урман ур., 33 йорт, Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында (http://leninogorsk.tatarstan.ru) «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru/) бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Лениногорск муниципаль районы
«Тимәш авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы Х.Х.Сөләйманова